КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 28 март г.Казань № 369

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга, шулай ук аларның гаилә әгъзаларына (шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат пенсиягә киткәннән соң да) медицина хезмәте күрсәтү тәртибе турында» 2006 ел, 7 август, 407 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга, шулай ук аларның гаилә әгъзаларына (шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат пенсиягә киткәннән соң да) медицина хезмәте күрсәтү тәртибе турында» 2006 ел, 7 август, 407 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 9 июль, 466 нчы, 2019 ел, 30 декабрь, 1270 нче; 2020 ел, 27 гыйнвар, 26 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктның өченче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга, шулай ук аларның гаилә әгъзаларына (шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат пенсиягә киткәннән соң да)

медицина хезмәте күрсәтү тәртибенең 2.1 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин